**СОВЕТ АЛЬДЕРМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422711, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Альдермыш, ул. Хабибуллина, 25

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛДЕРМЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422711, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Әлдермеш авылы, Хабибуллина урамы, 25

Тел./факс 8(84365) 79-4-03, e-mail:Alder.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**27 апрель 2021 ел** **№27**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә керми торган физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләрдәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Әлдермеш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Әлдермеш авыл җирлеге Советының 2021 елның 26 мартындагы 23 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә керми торган физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләрдәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында Нигезләмә»гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.3. беренче пунктын 3.2 пунктының икенче абзацы итеп түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Рөхсәт бирү мөрәҗәгать итүченең салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш, бурычы булмаган очракта гамәлгә ашырыла.»;

2) 5.4. пунктта «территориясендә» сүзеннән алда «Әлдермеш авыл җирлеге» сүзләре белән тулыландырырга;

3) 6.4. пунктның бишенче абзацында, икенче җөмләдә «башкарма комитеты тарафыннан» сүзләре алдында «Әлдермеш авыл җирлеге» сүзләре белән тулыландырырга;

4) 6 бүлек. «Яшел утыртмаларны зарарлаган һәм (яисә) юкка чыгарган (кискән, җимергән) өчен җаваплылык» 7 бүлеккә алыштырырга;

5) 7 бүлек. «Әлеге Тәртипнең үтәлешенә контроль» 8 бүлеккә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес

буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Т.С.Сабиров